| Республика Татарстан<br>Старо-Имянское сельское<br>поселение Сармановского<br>муниципального района | | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районынын Иске Имән<br>авыл жирлеге |
|---|---|---|

**КАРАР**
**20.03.2024 ел**

**КАРАР**
**№ 2**

«Иске Имән авыл җирлеге Сарысаз-Тәкермән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТӘ:**

1.2024 елның 30 мартында 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Сарысаз-Тәкермән торак пункты, Карл Маркс урамы, 1 в йорт адресы буенча урнашкан Сарысаз-Тәкермән авылы Мәдәният йорты бинасында «Иске Имән авыл җирлеге Сарысаз-Тәкермән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Иске Имән авыл җирлеге Сарысаз-Тәкермән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә ризамы:

1.Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында төзелеш материаллары сатып алу һәм зират коймасын урнаштыру буенча эш өчен түләү);
2. Торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); Сарысаз-Тэкермән торак пунктында вак таш япмасын ремонтлау (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, вак таш ташу һәм салу, грейдирование);
3. Электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрләрен,трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру);
4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
5. Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарның вакытлыча туплану урыннарын җыю (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Иске Имән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка чыгарырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Исламова

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ОГРН 1021601312974
Совет Старо-Имянского сельского поселения
Иске Имән авыл җирлеге Советы
ИНН 1636001989